**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 5 декабрендәге 4292 номерлы карары**

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсы турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 25 маендагы 2128 номерлы карары белән расланган 2016-2025 елларга Казан шәһәрендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль программасы нигезендә (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5316 номерлы, 2017 елның 4 апрелендәге 976 номерлы, 2018 елның 5 февралендәге 491 номерлы, 2018 елның 26 февралендәге 749 номерлы, 2018 елның 8 августындагы 4328 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 5933 номерлы, 2019 елның 13 маендагы 1705 номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 2711 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 3986 номерлы, 2020 елның 30 декабрендәге 3983 номерлы, 2021 елның 16 июлендәге 1750 номерлы, 2022 елның 27 гыйнварындагы 270 номерлы, 2023 елның 25 июлендәге 2088 номерлы, 2023 елның 19 декабрендәге 4172 номерлы, 2025 елның 7 мартындагы 628 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) **карар бирәм**:

1. Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында түбәндәге номинацияләрдә шәһәр конкурсы игълан итәргә:

- «Балалар һәм үсмерләр мохитендә терроризмны, экстремизмны һәм ксенофобияне профилактикалау буенча иң яхшы проект»;
- «Яшьләрне һәм гражданнарны деструктив һәм криминаль оешмаларга җәлеп итүгә каршы тору буенча иң яхшы проект».

2. Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә

социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсы турында нигезләмәне (1 номерлы кушымта) расларга.

3. Конкурс комиссиясе составын расларга (2 номерлы кушымта).

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 2 июлендәге 2817 номерлы «Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсы турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 5 декабрендәге
4292 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә түбәндәге номинацияләрдә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) уздыру максатларын, бурычларын һәм тәртибен билгели:

- «Балалар һәм үсмерләр мохитендә терроризмны, экстремизмны һәм ксенофобияне профилактикалау буенча иң яхшы проект»;
- «Яшьләрне һәм гражданнарны деструктив һәм криминаль оешмаларга җәлеп итүгә каршы тору буенча иң яхшы проект».

1.2. Конкурсны оештыручы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалата бүләк бирү буенча вәкаләтле орган – Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты.

Составы әлеге карар белән раслана торган конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) конкурсның эшче органы булып тора. Конкурсны оештыру өлешендә турыдан-туры эш башкаруны Комиссия сәркатибе гамәлгә ашыра.

1.3. Конкурста Казан шәһәре территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыручы гражданнар катнаша.

1.4. Комиссия тарафыннан конкурста җиңүчеләр дип танылган гражданнарга Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабына акчалата бүләк тапшырыла.

1.5. Акчалата бүләк 2016-2025 елларга Казан шәһәрендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль программасы чараларын гамәлгә ашыруга Казан шәһәре бюджетында 2025 елга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә тапшырыла.

## II. Конкурсның максатлары һәм бурычы

Конкурсның максатлары – гражданлык килешүен тәэмин итү эшендә гражданнарның ролен күтәрү һәм Казан шәһәрендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлдерелгән социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга булышлык итү.

Конкурсның бурычы – толерантлыкны, милләтара килешүне үстерү, яшьләр арасында экстремизм һәм террорчылык таралуны кисәтү, шулай ук деструктив психологик йогынтыга дучар булган балаларны һәм яшүсмерләрне кабаттан социальләштерү буенча иң яхшы проектларны ачыклау.

## III. Конкурсны үткәрү тәртибе, нәтиҗәләр ясау, конкурста җиңүчеләрне билгеләү һәм бүләкләү

3.1. Конкурсны уздыру турында мәгълүмат һәм нигезләмә Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) «Террорчылыкка каршы комиссия» өстәмә битендә агымдагы елда конкурс үткәрү турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә урнаштырыла. Башка затлар тарафыннан авторлыкка дәгъва кылуны булдырмау максатыннан, проектлар кергән саен, авторлар ризалыгы белән әлеге биттә Комиссиягә тапшырылган проектлар турында мәгълүмат урнаштырыла.

3.2. Конкурста Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм яшәүче 18 яше тулган Россия Федерациясе гражданнары катнаша ала.

3.3. Конкурста катнашырга теләк белдергән гражданнар, агымдагы елның 3 декабреннән дә соңга калмыйча, Комиссиягә конкурста катнашу турында гариза тапшыра. Конкурста катнашу өчен гражданнар Комиссия сәркатибенә (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3 йорт, 637 кабинет, тел.299-15-95) кәгазь чыганакта түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:

- әлеге нигезләмәгә 1 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча гариза;
- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә проект;
- паспорт күчермәсе (шәхси белешмәләр һәм яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүмат булган битләр);
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (3 номерлы кушымта).

3.4. Комиссия сәркатибе эш көне дәвамында Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының эш башкару идарәсенә керүче документларны теркәүне тәэмин итә һәм ике эш көне эчендә аларны, карап тикшерү өчен,

Комиссиягә тапшыра.

3.5. Гражданнар конкурска бер социаль әһәмияткә ия проектны үз эченә алган бер гариза тапшыра.

3.6. Әлеге нигезләмә белән билгеләнгән документларны тапшырган гражданнарга гына конкурста катнашырга рөхсәт ителә. Гражданнарны конкурста катнаштыру түбәндәгеләргә нигезләнеп кире кагылырга мөмкин:

а) документларны тапшырмау яки документларны тулы күләмдә тапшырмау;

б) документларның әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

в) документларны гаризалар тапшыру вакыты тәмамланганнан соң тапшыру.

3.7. Комиссия кергән материалларны карап тикшерә һәм гариза бирүчеләрне конкурста катнаштыру (катнаштырмау) турында карар кабул итә; әлеге карар агымдагы елның 10 декабреннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

Конкурс Комиссиясе, агымдагы елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча, конкурста катнашучыларга, кире кагу турындагы карарның күчермәсен теркәп, конкурста катнашуны кире кагу хакында хәбәрнамә юллый. Хәбәрнамә гаризада күрсәтелгән электрон почтага җибәрелә.

Комиссия конкурста катнашу рөхсәт ителгән катнашучылар тарафыннан тапшырылган материалларны, агымдагы елның 17 декабреннән дә соңга калмыйча, 2 номерлы кушымтада китерелгән конкурс критерийлары буенча бәяли һәм конкурста җиңүчеләр турында карар кабул итә.

3.8. Гариза бирүчеләрне конкурста катнаштыру (катнаштырмау) турында карар кабул итү, конкурс җиңүчеләрен билгеләү Комиссия утырышында Комиссия әгъзалары тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының кимендә 2/3 өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч тавыш булып тора. Комиссия утырышында рәис катнашмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

Конкурс Комиссиясе әгъзасы, гаризаларны карап тикшерә башлаганчы, Комиссия рәисенә конкурсның теләсә кайсы катнашучысына карата мәнфәгатьләр каршылыгы булу яки аның барлыкка килү ихтималы булу турында язмача хәбәр итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр каршылыгы ачыкланган очракта яки аның булуы турында

гариза алынганда, Комиссия әгъзасы әлеге катнашучының гаризасын бәяләүдән һәм аның өчен тавыш бирүдән кичекмәстән читләштерелергә тиеш.

Хәбәр ителгән мәнфәгатьләр каршылыгы һәм читләштерү турында мәгълүмат Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлә.

Гаризалары үз номинацияләрендә иң күп балл җыйган катнашучылар Конкурсның җиңүчеләре булып санала.

Конкурста катнашу өчен бер генә гариза керсә һәм проект конкурс таләпләренә һәм критерийларына туры килсә, гражданин җиңүче дип танылa.

Комиссия утырышы беркетмәсе Комиссия утырышы узган көннән алып бер эш көне эчендә рәсмиләштерелә, ул Комиссия рәисе яки утырышта Комиссия рәисе функцияләрен башкаручы урынбасар һәм Комиссия сәркатибе тарафыннан имзалана.

3.9. Конкурс нәтиҗәләре һәм анда җиңүчеләр турында мәгълүмат Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында «Террорчылыкка каршы комиссия» өстәмә битендә конкурста җиңүчеләр исемлеген раслаган көннән алып өч көн эчендә урнаштырыла.

3.10. Әлеге нигезләмәгә ярашлы рәвештә, бүлеп бирелгән финанслау кысаларында беркетмә имзаланган көннән алып бер ай эчендә җиңүчеләргә Комиссия беркетмәсе нигезендә акчалата бүләк тапшырыла:

- 100 мең сум – «Балалар һәм яшүсмерләр арасында террорчылыкны, экстремизмны һәм ксенофобияне профилактикалау буенча иң яхшы проект» номинациясендә җиңүчегә;

- 80 мең сум – «Яшьләрне һәм гражданнарны деструктив һәм криминаль оешмаларга җәлеп итүгә каршы тору буенча иң яхшы проект» номинациясендә җиңүчегә.

Акчалата бүләк суммасы физик затлар керемәнә салым тотып калуны исәпкә алмыйча исәпләнгән.

3.11. Конкурста җиңүчеләргә нәтиҗәләрне игълан иткән көннән алып өч эш көне эчендә әлеге нигезләмәнең 4 номерлы кушымтасында китерелгән форма буенча, банк реквизитларын күрсәтеп, акчалата бүләк күчерү турында гариза белән Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

3.12. Акчалата бүләк конкурс җиңүчеләреннән 3.11 пунктта күрсәтелгән гариза алынган көннән башлап 10 эш көннән дә соңга калмыйча күчерелә.

---

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 5 декабрендәге
4292 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсында җиңүчеләрне билгеләү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Б.Р.Алиев | комиссия рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе |
| И.П.Смирнова | комиссия рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе башлыгы |
| Р.Ә.Мөхәрьямов | комиссия сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлеге башлыгы |
| Комиссия әгъзалары: | |
| В.И.Яковлев | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе урынбасары – хокук идарәсе башлыгы |
| И.Н.Сарманов | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге башлыгы |
| Е.С.Ямбаршева | «Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесе директоры |
| Д.В.Сәйфуллин | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисенең беренче урынбасары |
| Е.В.Кисиль | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлеге баш белгече |

_____________________

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы граждannar арасында шәһәр конкурсы турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы граждannar арасында шәһәр конкурсында катнашуга гариза**

1. Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме: ______________________________
_____________________________________________________________________________.

2. Адресы: _____________________________________________________,
телефон номеры _________________, e-mail: __________________________________.

3. Проект исеме: ______________________________________________________.
Номинация атамасы: ___________________________________________________.
Проект авторы: _______________________________________________________.
Элемтә өчен мәгълүмат:_________________________________________________.

4. Проектка кыскача аннотация
Проблеманың тасвирламасы:______________________________________________
_____________________________________________________________________________.
Проектның максаты һәм бурычлары: ______________________________________.
Үткәрелгән чаралар планы: _____________________________________________.
Алынган нәтиҗәләр: ___________________________________________________.
Проектның зарурлыгын нигезләү: _________________________________________.

5. Гаризага түбәндәге материаллар теркәлә: ______________________________.

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә каршы булмавымны белдерәм.

Гражданинның имзасы______________________ / ______________________________/
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Дата:_________________________

Террорчылыкны һәм экстремизмны
профилактикалау өлкәсендә
социаль әһәмияткә ия проектларны
гамәлгә ашыруда катнашучы
гражданнар арасында шәһәр
конкурсы турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсында катнашучыларны бәяләү критерийлары**

| № т/б | Гаризаларны бәяләү критерийлары | Бәяләү (балл) |
|---|---|---|
| 1 | Проектның конкурс темасына туры килүе | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризага теркәп бирелгән башка документларны бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 2 | Проект хәл итәргә тиешле бурычларның актуальлеге | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризага теркәп бирелгән башка документларны бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 3 | Проект чараларының логикага нигезләнгән, үзара бәйләнешле һәм эзлекле булуы | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризага теркәп бирелгән башка документларны бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 4 | Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре булу, аларның проект бурычларына туры килүе | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризага теркәп бирелгән башка документларны бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 5 | Планлаштырылган чараларның проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә туры килүе | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризага теркәп бирелгән башка документларны бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 6 | Проект чараларының максатчан төркемне яхшыртуга йогынты ясау дәрәҗәсе | Баллар саны тапшырылган проектны, гаризага теркәп бирелгән башка документларны бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 7 | Эшләнгән сайт булу | Юк – 0, әйе – 1 |

Терроrчылыкны һәм экстремизмны
профилактикалау өлкәсендә
социаль әһәмияткә ия проектларны
гамәлгә ашыруда катнашучы
гражданнар арасында шәһәр
конкурсы турында нигезләмәгә
3 номерлы кушымта
(Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ____________________________________,

паспорт: сериясе _____ номеры ___________ _____ елның «____» _________________
(бирелү вакыты)

______________________________________________________________________________,
(документны биргән орган атамасы)

______________________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъекты вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))
түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ____________________________________,

паспорт: сериясе _______ номеры _____________ ______елның «____» ___________
(бирелү вакыты)

______________________________________________________________________________,
(документны биргән орган атамасы)

______________________________________________________________________________,
[ышаныч кәгазе яки әлеге вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган башка документ реквизитлары
(шәхси мәгълүматлар субъекты вәкиленнән ризалык алганда)]
2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә, конкурс уздыру һәм акчалата бүләкләү алу максатыннан, операторга – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенә, җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңартуны, үзгәртүне), алуны, файдалануны, тапшыруны (таратуны, бирүне, файдалану өчен рөхсәтне), шәхси үзенчәлекләрен юк итүне, тыюны, бетерүне, юкка чыгаруны кертеп, автоматлаштырылган режимда, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шәхси мәгълүматларымны, атап әйткәндә, түбәндәге белешмәләрне (кирәклесенең астына сызарга) эшкәртүгә ризалыгымны бирәм:

1) фамилия, исем һәм атасының исеме, яшәү урыны (теркәлү һәм факттагы) буенча адрес, электрон почта адресы һәм телефон номеры турында мәгълүматларны кертеп, анкета белешмәләре;

2) сериясен, номерын, бирелү датасын, документны биргән органның атамасын кертеп, паспорт яки шәхесне һәм гражданлыкны таныклый торган башка документ

турында белешмәләр;

3) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры турында белешмәләр;

4) мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы аерым шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС).

Шәхси мәгълүматларымны өченче як аша гына алып булган очракта, миңа, шәхси мәгълүматларны алуның максатларын, мөмкин булган чыганакларын һәм ысулларын күрсәтеп, бу хакта алдан хәбәр итәлергә һәм моның өчен шулай ук ризалык алынырга тиеш.

Миңа шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы булуым турында аңлатылды.

Ризалык аны имзалаган көннән гамәлгә керә һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатына ирешкән яки аны язмача формада кайтарып алган билгесез вакытка кадәр гамәлдә була.

___________________________________________________________________________

(имза, фамилия һәм инициаллар)

Ризалык бирү датасы: 20___ елның «____» ____________

Террорчылыкны һәм экстремизмны
профилактикалау өлкәсендә
социаль әһәмияткә ия проектларны
гамәлгә ашыруда катнашучы
гражданнар арасында шәһәр
конкурсы турында нигезләмәгә
4 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты Аппараты**
**җитәкчесе**
___________________________________
*кемнән*:____________________________
_________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
адресы: _________________________,
телефон номеры: ________________

**гариза**

Конкурста җиңүче буларак, миңа тиешле акчалата бүләкне _________________________________________________ банкындагы _______________________
(банк атамасы)
хисап номерына түбәндәге реквизитлар буенча күчерүне сорыйм: _____________________________________________________________________________________,
банкның идентификация коды (БИК)__________________________________________________,
банкның тәңгәлләштерү номеры (ИНН)/исәпкә кую сәбәбе коды (КПП)_________________________________/___________________________________________,
_____________________бүлекчәсендәге корреспонденция счеты _________________________,
төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН)/предприятиеләрнең һәм оешмаларның гомумроссия классификаторы (ОКПО) _____________________________________________________________.

____________________________________________________
(имза, фамилиясе, исеме, атасының исеме, дата)